**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**“06” апрель 2024 ел, № 11**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Үрнәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Үрнәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Үрнәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 11 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлегенең Үрнәк авылында гражданнар җыенының 2024 елның 06 апрелендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре яңа редакция белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү, Үзәк урамыннан Бакча урамына керү юлының нигезен төзү, Урман арты урамында сууткәргеч торбасын сүтү һәм урнаштыру, торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга.

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 690 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 365 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы

түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 365 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылында халык җыены булып узган, нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. Халык җыены нәтиҗәләре соравын яңа редакциядә кабул итәргә:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү, Үзәк урамыннан Бакча урамына керү юлының нигезен төзү, Урман арты урамында сууткәргеч торбасын сүтү һәм урнаштыру, торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту)?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга, карар кабул ителгән дип танырга».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк авылы, Урман урамы, 54А йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк авылы, Урман урамы, 1А йорты; Татарстан Республикасы, Арча районы, Үрнәк авылы, Бакча урамы, 3 нче йорт адреслары буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan. ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков